**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 28 февраль | № 121

г. Казань

«Россия Федерациясе субъектларында тикшерүдә тоту-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планын («юл картасын») раслау турында

«Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 ел, 26 декабрь, ФЗ-294 нче Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Россия Федерациясе субъектларында тикшерүдә тоту-күзәтчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыру» максатчан моделен Татарстан Республикасында гамәлгә кертү буенча чаралар планын («юл картасын») (алга таба – План) расларга.

2. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына Планда каралган чараларны тормышка ашыруны тәэмин итәргә.

3. «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 ел, 27 декабрь, ТРЗ-66 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына әлеге тикшерүдә тоту-күзәтчелек вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда күздә тотылган Планнан файдаланырга тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков